КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 15 июнь г.Казань № 719

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территорияләрне планлаштыру документлары проектларын карап тикшерү һәм аларга бәяләмәләр әзерләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 17 апрель, 310 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 25 май, 394 нче; 2020 ел, 17 апрель, 297 нче; 2020 ел, 23 ноябрь, 1050 нче; 2021 ел, 20 март, 152 нче; 2023 ел, 7 апрель, 427 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территорияләрне планлаштыру документлары проектларын карап тикшерү һәм аларга бәяләмәләр әзерләү тәртибенә, 3 пункттагы «территорияләрне планлаштыру буенча мәгълүмат системасында», «(алга таба – документ проектын кереп карау мөмкинлеген тәэмин итү турында хәбәрнамә)» сүзләрен «территорияләрне планлаштыру буенча федераль дәүләт мәгълүмат системасында», «(алга таба шул ук эзлеклелектә – территорияләрне планлаштыру буенча мәгълүмат системасы», документ проектын кереп карау мөмкинлеген тәэмин итү турында хәбәрнамә» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектын (ил оборонасы һәм дәүләт

иминлеге өлкәсендә Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектыннан тыш), Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары һәм территорияләрендә федераль әһәмияттәге объектлар урнаштырырга планлаштырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясенең расланган территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын килештерү һәм аларга бәяләмәләр әзерләү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 27 март, 172 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары» сүзләрен «вәкаләтле республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектын (ил оборонасы һәм дәүләт иминлеге өлкәсендә Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектыннан тыш), Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары һәм территорияләрендә федераль әһәмияттәге объектлар урнаштырырга планлаштырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясенең расланган территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын килештерү һәм аларга бәяләмәләр әзерләү тәртибендә:

исемендә «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1.1 пунктта «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга, татар текстында «территориаль планлаштыруның мәгълүмати системасында» сүзләрен «территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмати системасында (алга таба – территориаль планлаштыруның мәгълүмати системасы)» сүзләренә алмаштырырга;

II бүлекнең исемендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктта:

беренче абзацта «федераль дәүләт» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең түбәндәге органнарына» сүзләрен «түбәндәге республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына» сүзләрен «бүтән республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.4 пунктта «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органыннан» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.6 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарыннан» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнарыннан» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипнең 1 нче кушымтасындагы башисемендә «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипнең 2 нче кушымтасындагы башисемендә «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирлекләрнең генераль планнары проектларын, шәһәр округларының генераль планнары проектларын, тиешле генераль планнарга үзгәрешләр кертү һәм аларга 2022 һәм 2023 елларда бәяләмәләр әзерләү турындагы документлар проектларын карау тәртибен раслау турында» 2022 ел, 17 июнь, 582 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 30 декабрь, 1489 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Җирлекләрнең генераль планнары проектларын, шәһәр округларының генераль планнары проектларын, тиешле генераль планнарга үзгәрешләр кертү һәм аларга 2022 һәм 2023 елларда бәяләмәләр әзерләү турындагы документлар проектларын карау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары» сүзләрен «вәкаләтле республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «территориаль планлаштыруның мәгълүмат системасында» сүзләрен «территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин